
# Һөнәр сайлау- яуаплы эш


***Белем бирү максаты**:һөнәр сайлау проблемасы буенча лексик-грамматик күнекмәләрне кулланып,диалогик һәм монологик сөйләмгә чыгу.*

***Фикер үстерү максаты**:* чагыштыра белү, үз мөнәсәбәтеңне әйтә һәм дәлилли белү күнекмәләрен үстерү.

***Тәрбияви максат:укучыларга*** һөнәр сайлауда дөрес юнәлеш бирү; һөнәр ияләре турында мәгълүмат бирү; һөнәр сайлау җаваплы эш эш икәнен ассызыклау.



Нәрсә соң ул һөнәр?
Бу сорауга җавапны С. Ожеговның аңлатмалы сүзлегеннән карап әйтик :
Профессия-это у людей основной род занятий трудовой деятельности .



Нәрсә соң ул һөнәр?
Бу сорауга җавапны С. Ожеговның аңлатмалы сүзлегеннән карап әйтик:
Һөнәр – ул кешеләрнең төп шөгыле, хезмәт эшчәнлеге.

Ә хәзер миңа һөнәр сүзенең синонимнарын әйтегез әле.

*-Белгечлек*

**-Эш**

**-Профессия**

*-Хезмәт*

*-Кәсеп*

# Слайдларда нинди һөнәр иясе икәне әйтелә?











Табиб (нишли?) дәвалый.

Табиб (кайда?) дәвалый.

Табиб (ничәнче?) шифаханәдә дәвалый?

Табиб бишенче шифаханәдә (ничек?) дәвалый?

Табиб бишенче шифаханәдә (ни өчен?) яхшы дәвалый?

***Табиб бишенче шифаханәдә яхшы дәвалый, чөнки ул чын доктор.***

“Кенә, күп, яшьләр, буенча, үз, эшләми, һөнәрләре, техникум, лицей, бетергән, вуз. Бетергәндә, укырга, барасыңны, кирәктер, уйларга, турында, ә, яраткан, шуңа күрә, мәктәпне, кая, түгел, һөнәрең. Ул кадәр, кирәк түгел, кирәк, безгә, юрист, психолог, экономист, инженерлар, технологлар, төзүчеләр, токарьлар. Яшьләр, бит, сайламый, һөнәр, сайлый, уку йорты.”



**Спорт һәм туризм министры Марат Бариев әйткән сүзләр: “Яшьләр бит һөнәр сайламый, уку йорты сайлый. Техникум, лицей, вуз бетергән күп кенә яшьләр үз һөнәрләре буенча эшләми. Безгә ул кадәр юрист, психолог, экономист кирәк түгел, инженерлар, технологлар, төзүчеләр, токарьлар кирәк. Шуңа күрә мәктәпне бетергәндә, укырга кая барасыңны түгел, ә яраткан һөнәрең турында уйларга кирәктер”**

## ***Кем ул супервайзер?***

*Супервайзер-промоутерлар җитәкчесе. Ул рекламаны дөрес оештыру өчен, клиентлар белән ничек сөйләшергә, үз-үзеңне ничек тотарга, сатып алучыларга нинди юнәлеш бирергә кирәклекне аңлатучы;*

## ***Кем ул социолог?***

*Социолог-җәмгыятьтәге төрле катлауларның, төркемнәрнең фикерен һәм бер-берсенә йогынтысын өйрәнә;*

## Кем ул промоутер?

*Промоутерлар – рекламаны тормышка ашыручылар: листовкалар, купоннар тараталар, товар турында тулы мәгълүмат, аны куллану буенча киңәшләр бирәләр, бүләкләр тараталар, дегустацияләр уздыралар;*

## *Кем ул координатор?*

*Координатор-проект җитәкчесенең уң кулы-реклама оештыруны контрольдә тотучы*

## *Узган дәрестә өйрәнелгән сүзләр русча әйтелә*

Потребность- ихтыяж
Недовольство- канәгатьсезлек
Не по душе- күңелгә ятмау
Как вести себя-үз-үзеңне ничек тоту
Общественность- җәмәгатьчелек
Влияние- йогынты
Заслужить уважение- ихтирам казану

*Укучылар, психологлар һөнәрләрне 5 төргә бүлгәннәрен сез инде беләсез. Әйдәгез әле, бергәләп искә төшерик.*

*Человек - человек,*

*человек - природа,*

*человек - техника,*

*человек - знаковая система,*

*человек - художественный образ*

***Кеше – кеше.***

*Табиб, тәрбияче, укытучы, сатучы, чәчтараш*

***Кеше - табигать.***

Терлекче, агроном, бакчачы

***Кеше - техника.***

*Машина йөртүче, тимерче, эретеп ябыштыручы*

***Кеше - билгеләр системасы.***

*Тәрҗемәче, хисапчы, икътисадчы*

***Кеше - сәнгать образы.***

*Рәссам, доктор, буяучы, бизәүче*

**Бу сыйфатларга ия булган кеше нинди һөнәр төре сайлый ала?**

**Чыныккан, түземле, күзәтүчән, игътибарлы**

*Бу кеше - табигать дигән төркегә керә*

***Җитез, тиз фикерләүче, техника турында күп белә***

*Бу сыйфатларга ия булган кешегә нинди эш төре тәкъдим итә аласыз? (Кеше –техника)*

***Дәвам итик. Бу сыйфатлар кемгә хас? Эшлекле, яхшы оештыручы, кешегә тәэсир итәргә сәләтле, әдәпле, аралашучан.***

***Бу – кеше - кеше төркеменә керүче һөнәрләргә хас сыйфатлар***

***Дәвам итик. Бу сыйфатлар кемгә хас? Игътибарлы, түземле, сабыр, тырыш, белемле***

***Бу сыйфатлар кеше - билгеләр системасы дигән төргә туры килә***

***Бу сыйфатларга ия булган кеше кем булып эшли ала? Шат күңелле, җор телле, аралашучан, күзәтүчән***

***Кеше - сәнгать образы***

***Өй эше***

1. Яраткан һөнәреңә презентация эшләргә;
2. Яраткан һөнәреңә реклама ясарга;
3. Безгә таныш булмаган һөнәрләр турында мәгълүмат табарга (мәсәлән: титестер, актуарий һ.б.)

-Ә дәресне түбәндәге шигъри юллар белән төгәллисем килә:

Балачакны ташлап китәр чаклар
Сизелми дә килеп җитәчәк.
Балачаклар кире кайтмас
Алда юллар сезне көтәчәк.
Алда юллар – кайсын сайларга?
Төрле уйлар баштан үтәчәк.
Дөрес юллар сайлаганда гына
Котәр сезне матур киләчәк.